**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ БАЙРЯКИ-ТАМАКСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ЮТАЗИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
**ул.Новая, д.37, с. Байряки-Тамак, 423964**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЮТАЗЫ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БӘЙРӘКӘ-ТАМАК АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**
**Яңа урамы, 37йорт, Бәйрәкә-Тамак ав., 423964**

**Тел.:(85593) 5-13-25, факс:5-13-24, e-mail:Btam.Utz@tatar.ru**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

**№ 2** **2023 елның 31 гыйнвары**

2023елга Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Бәйрәкәтамак авыл җирлегендә җирләү буенча хезмәтләрнең гарантияле исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләрнең бәясен раслау турында

2003 елның 6 октябрендәге «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»гы 131-ФЗ санлы Федераль закон, 1996 елның 12 гыйнварындагы «Җирләү һәм җирләү эше турында»гы 8-ФЗ санлы Федераль закон, 2022 елның 27 гыйнварындагы «2022 елда түләүләрне, пособиеләрне һәм компенсацияләрне индексацияләү күләмен раслау турында» 57 санлы Россия Федерациясе Хөкүмәте карары, 2004 елның 28 июлендәге «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында»гы 45-ТРЗ санлы Татарстан Республикасы законы, 2007 елның 18 маендагы «Татарстан Республикасында җирләү һәм җирләү эше турында «Федераль законны гамәлгә ашыру чаралары хакында» 196 санлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Бәйрәкәтамак авыл җирлеге Советының 2019 елның 17 июлендәге 8 санлы карары белән кабул ителгән Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы “Бәйрәкәтамак авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Бәйрәкәтамак авыл җирлеге Башкарма комитеты к а р а р и т те:

1. 2023 елның 1 февраленнән Ютазы муниципаль районы Бәйрәкәтамак авыл җирлегендә әлеге карарның 1 нче кушымта һәм 2 нче кушымтасы нигезендә җирләү буенча хезмәтләрнең гарантияле исемлеген 7793,48 (җиде мең җиде йөз туксан өч сум 48 тиен) күләмендә билгеләргә һәм күрсәтелә торган хезмәтләрнең бәясен гамәлгә кертергә.
2. Ютазы муниципаль районы Бәйрәкәтамак авыл җирлеге Башкарма комитетының 2022 елның 31 гыйнварындагы «2022 елга Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Бәйрәкәтамак авыл җирлегендә җирләү буенча хезмәтләрнең гарантияле исемлеге буенча күрсәтелә торган хезмәтләрнең хакын

раслау турында»гы 8 санлы карарын үз көчен югалткан дип санарга.

1. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Бәйрәкәтамак авыл җирлеге территориясендә махсус мәгълүмат стендларында халыкка җиткерергә, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында түбәндәге адрес буенча урнаштырырга: http://pravo.tatarstan.ru, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының рәсми сайтында Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре Порталында Интернет-телекоммуникация челтәрендә түбәндәге адрес буенча урнаштырырга: http://jutaza.tatarstan.ru.

4. Әлеге карар рәсми халыкка игълан ителгән көннән үз көченә керә.

5. Әлеге карарның үтәлешен үз контролемдә тотам.

Бәйрәкәтамак авыл җирлеге башлыгы: Ф.В.Әхмәтов

ИНН 1642004868

Татарстан Республикасы
Ютазы муниципаль районы
Бәйрәкәтамак авыл җирлеге
Башкарма комитетының
2023 елның 31 гынварыннан
санлы карарына 1 кушымта

2023 елның 1 февраленнән җирләү буенча хезмәтләрнең
гарантияләнгән исемлеге бәясе

| Хезмәт исеме | Хезмәтнең бәясе (сумнарда) |
|---|---|
| 1. Күмү өчен кирәк булган документлар әзерләү. | 0,00 |
| 2. Җирләү өчен кирәкле табут һәм башка предметларны бирү һәм китерү | 3115,52 |
| 3. Мәрхүмнең җәсәден (калдыкларын) зиратка илтү | 952,3 |
| 4. Җирләү (кабер казу һәм күмү) | 3725,66 |
| Барлыгы | 7793,48 |

Татарстан Республикасы
Ютазы муниципаль районы
Бәйрәкәтамак авыл җирлеге
Башкарма комитетының
2023 елның 31 гынварыннан
санлы карарына 2 кушымта

2023елның 1 февраленнән җирләү буенча хезмәтләрнең
гарантияләнгән исемлеге бәясе

| Хезмәт исеме | Хезмәтнең бәясе (сумнарда) |
|---|---|
| 1. Күмү өчен кирәк булган документлар әзерләү. | 0,00 |
| 2. Мәетне кәфенләү, киендерү | 723,02 |
| 3. Җирләү өчен кирәкле табут һәм башка предметларны бирү һәм китерү | 2392,5 |
| 4. Мәрхүмнең җәсәден (калдыкларын) зиратка илтү | 952,3 |
| Җирләү (кабер казу һәм күмү) | 3725,66 |
| Барлыгы | 7793,48 |